КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 23 гыйнвар г.Казань № 29

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында мәктәп автобусларын нәтиҗәле файдалану чаралары турында» 2006 ел, 3 август, 400 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 29 ноябрь, 669 нчы; 2016 ел, 30 декабрь, 1070 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы белем алучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче пунктның икенче һәм өченче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Автобус 2017 елның 1 апреленнән гамәлгә кертелгән ГОСТ 33552-2015 «Балалар йөртү өчен автобуслар. Техник таләпләр һәм сынаулар ысуллары» таләпләренә, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Балалар төркемнәрен оешкан рәвештә автобуста йөртү кагыйдәләрен раслау турында» 2013 ел, 17 декабрь, 1177 нче карары белән билгеләнгән таләпләргә җавап бирергә тиеш.

Автобус кузовы сары төстә буялган булырга тиеш.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәктәп автобус маршрутын ачу турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2010 ел, 3 август, 615 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 20 октябрь, 831 нче; 2016 ел, 30 декабрь, 1070 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Мәктәп автобус маршрутын ачу турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.3 нче пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мәктәп автобусы – ГОСТ 33552-2015 «Балалар йөртү өчен автобуслар. Техник таләпләр һәм сынаулар ысуллары» таләпләренә җавап бирә торган махсуслаштырылган автотранспорт чарасы;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин